## Сентябрь аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 4.17 | 5.47 | 13.05 | 17.20 | 19.33 | 21.03 |
| 2 | 4.19 | 5.49 | 13.05 | 17.18 | 19.31 | 21.01 |
| 3 | 4.21 | 5.51 | 13.05 | 17.16 | 19.29 | 20.59 |
| 4 | 4.22 | 5.52 | 13.05 | 17.15 | 19.26 | 20.56 |
| 5 | 4.24 | 5.54 | 13.05 | 17.13 | 19.24 | 20.54 |
| 6 | 4.26 | 5.56 | 13.05 | 17.11 | 19.21 | 20.51 |
| 7 | 4.28 | 5.58 | 13.05 | 17.09 | 19.19 | 20.49 |
| 8 | 4.29 | 5.59 | 13.05 | 17.07 | 19.17 | 20.47 |
| 9 | 4.31 | 6.01 | 13.05 | 17.05 | 19.14 | 20.44 |
| 10 | 4.33 | 6.03 | 13.05 | 17.03 | 19.12 | 20.42 |
| 11 | 4.34 | 6.04 | 13.05 | 17.01 | 19.09 | 20.39 |
| 12 | 4.36 | 6.06 | 13.05 | 16.59 | 19.07 | 20.37 |
| 13 | 4.38 | 6.08 | 13.05 | 16.57 | 19.05 | 20.35 |
| 14 | 4.40 | 6.10 | 13.05 | 16.55 | 19.02 | 20.32 |
| 15 | 4.41 | 6.11 | 13.05 | 16.53 | 19.00 | 20.30 |
| 16 | 4.43 | 6.13 | 13.05 | 16.51 | 18.57 | 20.27 |
| 17 | 4.45 | 6.15 | 13.05 | 16.49 | 18.55 | 20.25 |
| 18 | 4.47 | 6.17 | 13.05 | 16.47 | 18.52 | 20.22 |
| 19 | 4.48 | 6.18 | 13.05 | 16.45 | 18.50 | 20.20 |
| 20 | 4.50 | 6.20 | 13.05 | 16.43 | 18.47 | 20.17 |
| 21 | 4.52 | 6.22 | 13.05 | 16.41 | 18.45 | 20.15 |
| 22 | 4.53 | 6.23 | 13.05 | 16.39 | 18.43 | 20.13 |
| 23 | 4.55 | 6.25 | 13.05 | 16.37 | 18.40 | 20.10 |
| 24 | 4.57 | 6.27 | 13.05 | 16.35 | 18.38 | 20.08 |
| 25 | 4.59 | 6.29 | 13.05 | 16.33 | 18.35 | 20.05 |
| 26 | 5.00 | 6.30 | 13.05 | 16.31 | 18.33 | 20.03 |
| 27 | 5.02 | 6.32 | 13.05 | 16.28 | 18.30 | 20.00 |
| 28 | 5.04 | 6.34 | 13.05 | 16.26 | 18.28 | 19.58 |
| 29 | 5.05 | 6.36 | 13.05 | 16.24 | 18.26 | 19.56 |
| 30 | 5.07 | 6.37 | 13.05 | 16.22 | 18.23 | 19.53 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре үзерләде, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*

**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

# Кыйбла

„БЕРДӘМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 8
2012 ел
август

№ 35 (1162), 25 август 2012 ел

***ВӘГАЗЬ***

# Яхшы сүзне аңлау өчен

Әссәламүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ, мөхтәрәм дин кардәшләр!

Адәм баласы акылын тирәнтен эшләтсә, бу дөньяның иге-чиге юклыгын, аның катлаулылыгын, төрлелеген һәм төрле төстә булуын күрер. Алай гына да түгел, шушы иге-чиге булмаган дөньяда барлык нәрсәләр бер-берсе белән зур бәйләнештә һәм мөнәсәбәттә яшиләр. Монда тәртип, үзара бәйләнеш, бер канунга буйсыну һәм эчке төзеклек күренә. Әгәр дә яхшылап акыл белән уйланса, әлбәттә, дөнья тәртибе үзеннән-үзе булган дип уйларга урын калмый.

Кеше ике хәлдә яши: иманлы һәм имансыз (юньсез) булып. Ә инде болар арасында - коточкыч хәтәр чокыр. Иманлы кеше үзен чорнап алган дөньяда Аллаһының чиксез санлы галәмәтләрен күрә, ә имансызга Аллаһының галәмәтләрен күпме күрсәтсәң дә, ул барыбер, болар үзләре булган, диячәк. Коръән-Кәримдә әйтелә: «Мәрьям улы Гайсә галәйһиссәлам Бәни Исраилгә килгәч, сукырларны күрә торган итә, ала тәнлеләрне сәламәтләндерә, үлекләрне терелтә...»

Аллаһы Тәгалә кешене җиргә Үзенең хәлифе итеп куйган, бүтән мәхлуклар арасында сайлау ирекләге бирелгән, һәркем тормыш юлында кемгә табынуны үзе сайлый. Кеше бөтен гомере буена туктаусыз сынау үтә, чөнки аның яратылышы – сыналу һәм үзен барлыкка китерүчегә табыну өчен. *«Малларыгызда бәла-каза күреп, үзегез дә бәла-казага очрап, әлбәттә, сыналырсыз, һәм сезгә кадәр китап бирелгән кешеләрдән һәм динсезләрдән, әлбәттә, мәсхәрә кыла торган сүзләрне күп ишетерсез. Әгәр боларның барына да сабыр итеп чыдасагыз һәм Аллаһыга тәкъвалык кылсагыз, әлбәттә, бу эш бик олы мөһим эштер»,* – дип боера Аллаһы Тәгалә «Әәл Гыймран» сүрәсенең 186 нчы аятендә.

Кеше - Аллаһы Тәгалә колы, Аның тарафыннан ризыклана, Аның тарафыннан үтерелә. Кеше тәненең барлык әгъзалары төгәл, Аллаһы Тәгалә канунынннан тайпылмый яшиләр. Нинди генә вакыйгалар булмасын, кеше тереклеге Аллаһы Тәгалә канунынннан чыга алмый һәм Аннан башка яши алмый. Коллык дигән сүз кешене тетрәндерә, ул бу сүзне тыныч кына кабул итә алмый. Әлбәттә, бу шулай, әгәр дә кеше үзе барлыкка китергән нәрсәләргә кол булса (бүтән бер кешегә, байлыгына, исертә торган нәрсәләргә, үзенең нәфесенә)! Әгәр кеше үзен бары тик Аллаһы Тәгалә колы дип кенә хисапласа, ул вакытта аның рухи көче арта, кеше тормыш юлын дөрес сайлый, күркәм әхлаклы була һәм шул сәбәптән ике дөньяда тирән ихтирамга ирешә, иншаллаһ.

Кешенең рухы һәрвакыт берәр нәрсәгә табынуга мохтаҗ, аның рухы түрендә табыну ихтыяҗы бар. Ул Аллаһы Тәгаләгә ышанмаска, динне кабул итмәскә, дөреслектән читкә качарга мөмкин, шулай булса да аның рухы барыбер берәр нәрсәгә табынырга омтылачак, чөнки аның рухы шулай яратылган. Аңа генетик яктан кемгә табынырга тиешлеге күрсәтелгән, асылда бер Аллаһы Тәгаләгә. Әгәр кеше шул генетик күрсәтелеш белән дөрес кулланса, аның рухы дөреслеккә табына, чын азатлыкны яулый, Аллаһы Тәгалә кушканнарны үти һәм Аллаһы Тәгаләнең хәлифе була.

Кешене бар итеп, аны җиргә хәлиф итеп куйганда, Аллаһы Тәгалә кешелек дөньясының барлык ихтыяҗларын чорнап алырлык дәрәҗәдә канун-законнар чыгарган: сәясәт, икътисад, хокук, әхлак һ.б. өлкәләрдә. Бу кануннарны Аллаһы Тәгалә кешеләргә Үзенең пәйгамбәрләре аша ирештереп торган. Ул пәйгамбәрләр кешеләрнең үз араларыннан сайланган.

Аллаһы Тәгалә илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм - ахырзаман пәйгамбәре, аннан соң бүтән пәйгамбәр булмаячак. Кешелек һәм җеннәр дөньясына тулы, бүтән үзгәртелмәячәк ислам дине алып килгән, шуңа күрә кыямәт көненә кадәр кешеләр һәм җеннәр үз гамәлләрен, Ул алып килгән кануннар буенча үлчәргә тиеш булачак. Бу кануннар – Коръән-Кәримдә (Аллаһы Тәгалә сүзләрендә) һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм эшләрендә, сүзләрендә, ягъни сөннәтендә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Мин сезгә ике нәрсә калдырам, әгәр шуларга бик ныклап ябышсагыз, бервакытта да адашмассыз: Аллаһының Китабын һәм Аның пәйгамбәренең сөннәтен».

*«Аллаһы Тәгалә биргән малны Аллаһы юлына биреп ахирәтне кәсеп ит, дөньядан үз өлешеңне онытма, ахирәтең өчен гамәл кыл»,* – диелә Коръән-Кәримдә («әл-Касас»